# Мәйдан Чаллы

әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал

9 / 2014
сентябрь

Сирень Якупова



4 612750 670196

ИҖАТЫНА
БЕР КАРАШ

Факил САФИН,

*2009 ел*

# Ак җилкәнле шигырьләр

*(Сирень Якупованың «Яшәү сере» исемле китабы хакында уйланулар)*

Татарстан китап нәшрияты укучыларны өр-яңа шигырь җыентыгы белән сөендерде. «Яшәү сере»... Шагыйрь Сирень Якупованың затлы нәшриятта дөнья күргән беренче китабы. Хәзер күпләр китап чыгара, арада чын шагыйрь җаныннан яралып, үзгә асылташ мисалында булырлыклары сирәк очрый. Нәкъ шушы сирәкләр генә әдәби хәзинәбезнең бер өлешенә әверелә. Сиреньнең китабы шушы хисаптан. Ул шигърияткә очраклы рәвештә килеп кергән кеше түгел. Таланты өстенә, биографиясе дә бар дип авыз тутырып әйтергә була. Күргән-кичергәннәре, югалту-табышлары, ягъни биографиясе булган каләм иясенең язганнары язмыш каегы сайда йөзүче шигырьчеләрнекеннән нык аерылып тора шул. Беренчедән, андыйлар кыланып язмыйлар, шигырь ясап азапланмыйлар, дөньяны шаккатырам дип тә хыялланмыйлар, ялган пафосның эзе дә юк. Ә менә язганнары җәлеп итә, шигырьдән шигырьгә болай гына күчеп булмый. Соңгы вакытта узгынчылар – шигырь язучылар күбәеп китте. Шигырь язган өчен шагыйрь булмыйлар, шагыйрь булган өчен шигырь язалар. Бу – аксиома, хәзер аңа төкереп тә бирмиләр. Аңламаганнар өчен чын бәла ул.

Сирень Якупова Әлмәт районының Түбән Абдул авылында туып-үскән кыз. Шактый еллар Чаллы каласында, КАМАЗ заводында эшләде. Хәзер «Шәһри Чаллы» газетасы хезмәткәре. Аны туксанынчы еллар уртасыннан беләм дип әйтә алам – шәһәрдә чыгып килүче газета, журналларда шигырьләре күренә башлады, вакыт тапса, «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә дә килә иде. Язганнарыннан гына түгел, күзләреннән дә шигърияткә очраклы килеп кермәгәнлеге күренеп тора. Тыйнак, ләкин үзсүзле, тәнкыйть иткәнне яратып бетермәсә дә, кутәрелеп бәрелми, уйлана, эзләнә. Тора-бара шигырьләре республика матбугатында да басыла башлады. Чаллы нәшриятларында ике китабы басылып чыкты. Инде Казан нәшрияты да аны игътибарсыз калдырмады. Иҗат диңгезендә ерактан гына шәйләнгән Сирень Якупованың Ак җилкәнен без инде ап-ачык күрәбез шикелле.

Китапка килсәк, беренче шигырьләр үк сокландыра. Язмыш җилкәне ак шикәрдән аклы, хыяллары таулардан да биек шагыйрь укучыга бер-бер артлы яшәү сере ачарга тотына.

... Туган йортым...
Менсәм аның түбәсенә,
Бер шигем юк түбәм күккә тиясенә...

Хисләрнең төзек хәрәкәттә, эзлекле булуы шигырьне җегәрле итә. Беренче шигырьдән башлап китап ахырына кадәр укучыны шушы төзеклек, хис-

ләрнең чынлыгы озата. Бу шигырьләр ышандыра, тулысы белән биләп, үзләренә тартып торалар.

Шагыйрь дөнья белән сөйләшә. Галәм – чиксезлек. Шагыйрь күңеле хистойгыда һәм уй-хыялда чикләрне үтеп, күкнең җиденче катына якыная ала икән – инде бу илаһи гамь, илаһи яну, илаһи мәхәббәт. Ясалмалык барлыкка килмәсен дә, чама хисен югалтмау гына кирәк, аның өчен исә акылның уяу булуы зарур. Талантлы шагыйрь чиксезлек һәм яшәү өчен бирелгән вакыт аралыгында гармония булдыра алуга сәләтле. Табигать-Вакыт-Күңел бердәмлеге матур (сагышлы булсалар да) табышларга китерә.

Йөгермәдем, ашыкмадым бер дә,
Ләкин йөгергәннәр белән бергә
Килеп кердем сары көзгә.

Шигърият дилбегәсен үз кулларында нык тотучы алтмышынчы елгы шагыйрьләр тавышы ишетелеп киткән кебек. Акыл өстә, хис исә тирәнгәрәк яшеренгән. Димәк, буш урында тумый шигырь. Элгәрләр әзерләгән уңдырышлы туфракка төшкән. Сурәттә, тасвирда традицияләрне үз итеп, үз сукмагыңны салу җиңел эш түгел.

Сирень тормышка, уйлап тапкан шигъри дөньясына кечкенә итеп уйган тәрәзә аша түгел, кайнап торган тормышка зур тәрәзә – үзе күргән, үзе кичергәннәр аша карый белә. Дөнья кеше алдына нинди генә сынаулар китереп куйса да, ул кеше биеклегендә кала алырга тиеш. Яшәү – кешедән рухныклыгы таләп итә дигән фикер, идея, шигырьдән шигырьгә күчеп, тоташ агым хасил итә. Мин сер дигәндә, безне сискәндерергә, уйланырга этәрүче бер яңалыкны күздә тотам. Шигырьдә сер, ягъни яңалык иҗат вакытында, көтелмәгәндә туа. Шагыйрьнең йөрәк тибешен ишетү, аның күңел дөньясын тою гаҗәп кызык бит. Иҗатта кеше рухы күренергә тиеш!

Абынсам да бик еш, егылсам да,
Еласам да шуңа үкереп,
Чит-ят күзләр күреп өлгергәнче
Тора алдым һәрчак сикереп.

Яшәү сере шулай шигырьдән шигырьгә ачыла бара. Ихласлыкка ни җитә! Кайберәүләрнең мин-минлек, шапырыну, «эт койрыгыннан да төз булучанлык», ялган җилкәнү-яскану, шөһрәтлеккә омтылу бөркелеп торган тезмәләрен укып, баш түнә башлый. Сирень Якупова исә кабаланмый, каударланмый һәм иң мөһиме – кабатланмый сер чишә дә чишә. Шагыйрьнең шәхси өлгергәнлеге, күңеленең матурлыгын тоеп җан кинәнә.

...Бер зарым юк сезгә, и кешеләр!
Бер үпкәм юк сиңа, и дөнья!

Көтелмәгән борылышлар сокландырып куя. «Җәйге уйлар», «Таган», «Балалар уенын күзәткәндә» һәм башка күп шигырьләрдә шундый көтелмәгәнлек күзәтелә. Бу шагыйрь стиленең бер үзенчәлеге. Стиль дәрәҗәсендә сүз кузгатыла икән, димәк, бу шигырьләрнең җаны, төсе-кыяфәте, сурәте бар дигән сүз. Димәк, шигырь иркен сулышлы, ул мөстәкыйль хәлдә яшәргә сәләтле. С.Якупованың шигырьләре табышларга бай. «Җир – Кояшның кызы. Мин Җирнеке. Кояш миңа әби буламы?» – дип башланган шигырь болай тәмамлана:

Җир – Кояшның кызы, мин оныгы.
Икебез дә очар күбәләк.
Бәхетлегә дөнья түгәрәк дип,
Әйләнәбез Кояш тирәләп.

Кайсы шагыйрь мондый юллардан баш тартыр икән?.. Бу юллар табигый да, ихлас һәм, ни хикмәт, аларда бераз

сабыйлык та бар. Катлаулы фәлсәфәгә этәрә торган мәңгелек кыйммәтләр хакында болай гади генә әйтеп бирүчеләр күп булса үзе дә ул! Иҗатның үз йөзе барлыгына (индивидуальлегенә) ишарә инде бу.

Татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге, туган тел, ил язмышы турында уйлаганда Сирень үзенең гүзәл холыклы, бу мәсьәләдә үз үлчәме, үз фикере булган, милләтне чын күңелдән кайгыртучы шәхес икәнен күрсәтә.

Бер хакым юк халкым телсез диеп,
Җирсез диеп шигырь язарга.
Тик хакым бар һәрбер татар җанын
Туган телгә төреп назларга.

Шулай гына булырга тиеш. Башкача булса, үз халкыңнан йөз чөерү, аңа кирәкмәгән гаеп өю хыянәткә тартым гөнаһ булыр иде. «Бетәбез, халык – сарык, милләт – бәрәңге колы» дип өзми-куймый лаф оручы «бәгъзеләрдән» гарык булдык инде. Соңгы вакытта милләткә яңа каһарманнар тәкъдим итеп, башка шәхесләрне юкка чыгарырга маташуларның да шаһиты бит без. Милләт аңына шикле рух сеңдерелә, сак булырга кирәк. Үзләрен һәрнәрсәдән өстен итеп күрергә җилкенгән кайбер кызган башлар әле тагын ниләр генә уйлап чыгармаслар... Шәхесләре имгәтелгән, вакланган, зирзибәр китерелгән милләтнең киләчәге өметле була аламы? Бүген берәүләрне юкка чыгарырлар, иртәгә икенчеләрне. Халык иң кара елларда да үз язмышын якты елларга алып барачак ак җилкәннең барлыгына ышанычын югалтмаска тиеш. Империячел реакция елларында бигрәк тә. Дәверне сайлап алмыйлар, нинди хәлдә дә барлыгыңны саклап калу өчен көрәшне туктатмаска, бердәмлекне җуймаска кирәк. Халык корабын «мин-минлекле» бер-ике «бурлак» белән генә, күпме көчәнсәң дә, ирекле, иркен елларга өстерәп илтеп куеп булмаячак.

Ил, халык язмышы турында, әйбәт тынгысызлыктагы, ягъни гүзәл гамьле шигырьләрне укыганда, Сиреньнең милли рухлы, пык куллы каләм остасына әверелеп баруын тоеп була. Хисләр дә өскә бәреп чыга, шагыйрь йөрәге шикелле кайнар, чынбарлык кебек кырыс алар.

Канлы шигырем бусын палач күзен,
Мирас булсын җаным татарга!
Күңелемдә таулар биеклеге,
Таудан биек өмет Ватанга.

«Татар биеклеген канында йөрткән» шагыйрьнең һич кенә дә «сөт калыр, Ватан китәр» дип утырасы килми. Сөтсез калу – мәнсезлек булса, Ватансызлык мескенлек инде ул. Бүгенгебез – ярты мескенлек, әле аны да саклап кала алу кирәклеген уйлы һәркем белә бит...

«Тау», «кан», «тамырга тиеп киткән пычак» кебек образлар һәм тәгъбир кулланып язылган шигырь тәэсирле. Шагыйрь йөрәге бәргәләнә, бүгенге халәттән чыгарга юл, чаралар эзли. «Нишлим, нишлим?» дип өзгәләнгән шагыйрь күңелен шулкадәр юатасы килә, әмма юатыр сүзләр табуы гына кыен. Әлегә халкыбызны якты киләчәккә алып китәр ак җилкән хыялларда гына... Шулай булса да, өмет сүнмәскә тиеш.

Сирень Якупова шигъри сүздә, сурәттә традицион алымнарны үз итеп яза. Күп белгечләр фикеренчә, шигырьне шигырь иткән мөһим нәрсәләр – метафора һәм аһәң. Анна Ахматова шигырь үлчәменә зур игътибар бирә (бигрәк тә поэмаларда), образлылыкка ирешүдә метафора – сәнгати көчемлелек көтелмәгән күзаллауларга китерә, шигырьгә накал – җегәр өсти. Мета-

фора белән канатланган шигырьнең үтемлелек дәрәҗәсе күп мәртәбә артып китә. Сирень үзенең шигырьләрендә ике принципны – күчемлелек һәм янәшәлекне бер яссылыкка куя. Империячел бумактагы ил язмышы – эт язмышы, «чишмә – җирнең шатлык яше, диңгез – кайгы яшедер» кебек юллар сискәнүле тойгы уятып кына калмыйлар, куе буяулы поэтик сурәт тудыруга да хезмәт итәләр.

Шагыйрь йөрәгендә кайнарлыгы сүрелмәс, газиз, тылсымлы бер урын бар. Ул әти-әнигә, туган якка, туган нигезгә булган изге хисләрдән кабынган сүнмәс учакны хәтерләтә.

Җанны ярып үлән исе керә,
Чәчәк төсе тула күзләргә.
Җилфер-җилфер күбәләкләр куна
Чыктан юешләнгән тезләргә.

Туган якка багышланган шигырьләрендә без инде йомшак, мамык телле тасвирны күрәбез. Таныш, тансык хисләр. Чынлыкта һәрбер кеше туган җиргә, җанга газиз кешеләргә тугрылыкта сынала бит. Шигырь юллары ипле, шул ук вакытта гади дә, тылсымлы да.

Шигырь – сер ачу дигән идек. Сер ачуны дәвам итәбез. «Бәхеттән балкып нур чәчә / Әллә ай, әллә йөрәк», «Биеп тора җанда чабышкы ат, / Соңгы булып барыбер килмәмдер!», «Шәл мамыгы очканга да / Алдана тиле күңел», «Бушлыкның да җанны сытып сыгар / Авырлыгы барын белмәдәм»... Болар барысы да кеше җаны, кеше күңеле хакында тирән бер тоем белән язылганнар, уйга уй ялгана, хис-кичерешләрнең караш һәм акыл иңләп бетермәслек тере чылбыры барлыкка килә. Бу чылбырның бер очы сабый чакның татлы хыялларыннан үсеп чыкса, икенче очы кая барып ялганадыр, анысын Ходай белә. Тәндә җан, башта акыл бар чагында яшәү чылбыры үсеш, үзгәрештән туктамый. Шигырьләрдән күренгәне шул – гомер чылбырына күңелнең һәр халәте, тормышның һәр мизгеле ниндидер төсмер өсти, караш-лар иркенәя, хәрәкәт тотрыклы үзгәрә бара. Юкка гына шагыйрь «Минем җанга иксез-чиксез / Дала киңлеге кирәк», димидер. Кысалардан азат булган саен шагыйрьнең язу куасе көчәя, аның шигъри талантына ныграк ышанасың. Гамьле кешенең иң гүзәл максаты – гомерне заяга уздырмау, яшәүнең мәгънәле, дәвамлы булуына ирешү. Бу фәлсәфә Сирень Якупованың яшәү кредосы.

Тормышның нигезендә ярату ята. Яратып, яратылып яшәү ул үзе шигырь, өзелмәс җыр. Ярату хакында хисләрне тугарып язучы хатын-кыз шагыйрьләрдән аермалы буларак, Сирень бу темага бик сак кагыла, чама дигән нәрсәне белеп эш итә. Шулай да, язсам, язарлыгым бар дигәндәй, бер шигырь чагылып китте: «Җил учына салам йөрәкне», – ди ул. Җил – сер ачу гына түгел, ул сөюнең гаҗәеп көчен дә белдерә кебек, җил – сагыш, җил – кире кайтарып булмаслык югалту да, җил – хәбәр дә... Үз-үзеңне аңларга омтылган җан, хиссиятнең мең дә бер төсмерен табып алып, аны шигырь биеклегенә күтәреп җибәрә. «Ак бәхетнең соңгы ак тузаны / Кочып елый бугай тиземне»... Шигырьдәге серне чишеп кара син! Шулай да... күңел «Кар кызы ялваруы» кебек шигырьләрнең күбрәк булуын тели. Тыелгысыз хисләрне гел генә ак кышларның ак карына күмеп, суытып яшәү шагыйрьләрчә түгел кебек.

«Яшәү сере» китабындагы һәр шигырь аңлау-аңлашу юлында истә калырлык ачыш сыман. Тик табышлардан канәгатьләнеп, ярты юлда туктарга җыенмый Сирень.

Йә күбәләк, йә гөл булып
Туасы мөллә Җиргә?
Белер өчен галәм серен.

Дөньяны капма-каршы бергәлек бөтен итеп саклый. Ир кеше – хатын-кыз заты, төн белән көн, Җир һәм Кояш, ут һәм су, ак һәм кара... Саный китсәң, хисапсыз. Гап-гади җир кешесе дә, даһилар да шушы аерылмас бергәлекнең серен эзлиләр. Шагыйрьнең теләге бер генә – шушы гармония җуелмасын, көннәр гөлгә төренеп, төннәр йолдызларга коенган хәлдә, миллион-миллион еллар яшәсен, кеше җанына бәхет кошы килеп кунсын, ил-көннәр имин булсын, һәр халык ирекле тормыш корсын. Кояш астында барыбызга да урын җитәрлек. Күңелне алга җилкендергән ак җилкәнне давыллар екмасын, тормыш корабында серле кыйтгалар ача-ача һаман алга, киләчәк якты елларга карап йөз дә йөз.